Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге
Башкарма комитеты
карары

№11046
20.10.2026

«Осталык та, илһам да»
шәһәр һөнәри осталык
конкурсы үткәрү турында

Башкарма комитетының 2025 елның 19 октябрендәге 8861 номерлы Карары белән расланган 2026-2028 елларга Яр Чаллы шәһәрендә мәдәниятне үстерү муниципаль программасын үтәү йөзеннән, сәнгать белеме бирү системасының кадрлар потенциалын саклау һәм үстерү максатында

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның мәдәният идарәсенә өстәмә белем бирү оешмалары укытучылары, концертмейстерлары һәм җитәкчеләре арасында «Осталык та, илһам да» шәһәр һөнәри осталык конкурсын (алга таба – конкурс) 2026 елның октябре-декабрендә үткәрергә.

2. Расларга:

1) конкурс үткәрү турында нигезләмәне, 1 нче кушымтада каралганча;

2) конкурсны әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру комитеты составын, 2 нче кушымтада каралганча.

3. Башкарма комитетның финанс идарәсенә конкурсны үткәрү буенча чыгымнарны финанслауга акча бүлеп бирүне 2026 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетының «Мәдәният» 0801 бүлегендә (бүлекчәсендә) каралган акчалар хисабына 150 000 (бер йөз илле мең) сум күләмендә, 3 нче кушымтада каралганча тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары В.Х. Харисовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2026 елның 20 октябрендәге
11046 номерлы карарына
1 нче кушымта

«Осталык та, илһам да»
шәһәр һөнәри осталык конкурсын үткәрү турында
нигезләмә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. «Осталык та, илһам да» һөнәри осталык конкурсы (алга таба – конкурс) Яр Чаллы шәһәренең өстәмә белем бирү оешмалары укытучылары, концертмейстерлары һәм җитәкчеләре арасында сәнгать белеме бирү системасының кадрлар потенциалына ярдәм күрсәтү һәм аны үстерү максатында үткәрелә.

2. Башкарма комитетның мәдәният идарәсе конкурсның оештыручы булып тора.

3. Конкурсның төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

1) Яр Чаллы шәһәре хезмәт базарында өстәмә белем бирү оешмалары укытучыларының конкурентлык сәләтен арттыру;

2) укытучыларның, концертмейстерларның һәм җитәкчеләрнең квалификациясен күтәрүгә булышлык итү, аларның иҗади активлыгын стимуллаштыру;

3) талантлы яшь белгечләрне ачыклау, аларга ярдәм итү һәм бүләкләү;

4) социаль статусны күтәрү һәм педагог һөнәре турында уңай җәмәгать фикере формалаштыру.

2 бүлек. Конкурсны оештыру һәм үткәрү тәртибе

4. Конкурсны әзерләү һәм үткәрү өчен составы Башкарма комитет карары белән раслана торган оештыру комитеты төзелә.

5. Оештыру комитеты түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашыра:

1) конкурсның бурычларын һәм үткәрү тәртибен аңлата;

2) катнашучылардан заявкалар һәм конкурс материалларын кабул итә;

3) жюри составын формалаштыра һәм аның функцияләрен билгели;

4) конкурсның этапларын үткәрү графигын төзи;

5) конкурс документларын алып бара;

6) бүләкләү тантанасын оештыра.

6. Конкурс өч турда үткәрелә:

1) 1 тур (сайлап алу) – урынга барып, өстәмә белем бирү оешмаларында үтә;

2) 2 тур (читтән торып) – оештыру комитеты һәм жюри әгъзалары катнашучыларның заявка материалларын дистанцион форматта карап тикшерә;

3) 3 тур (йомгаклау) – жюри әгъзалары урында үтә торган форматта конкурста катнашучылар арасында блиц-турнир үткәрә.

7. Конкурсның барлык турларының нәтиҗәләре буенча Гала-концерт үткәрелә.

3 бүлек. Конкурс номинацияләре

8. Конкурс түбәндәге төп номинацияләр буенча үткәрелә:
- «Иң яхшы укытучы»;
- «Иң яхшы концертмейстер»;
- «Иң яхшы җитәкче».

9. Яшь белгечләрдән заявкалар булганда (3 елга кадәр педагогик эш стажы булган, 35 яшькә кадәрге яшьтәге) оештыру комитеты карары белән «Иң яхшы укытучы» һәм «Иң яхшы концертмейстер» номинацияләре кысаларында «Һөнәри дебют» махсус подноминациясе гамәлгә куела.

10. «Иң яхшы укытучы», «Иң яхшы концертмейстер» номинацияләрендә һәм «Һөнәри дебют» подноминациясендә катнашуга Башкарма комитетның мәдәният идарәсе карамагындагы учреждениеләрнең - өстәмә белем бирү оешмаларының - төп хезмәткәрләре булган, урта махсус яки югары белемгә ия педагогик хезмәткәрләр кертелә. Төп номинацияләрдә катнашучыларның яше һәм стажы чикләнми.

11. «Иң яхшы җитәкче» номинациясендә катнашуга Башкарма комитетның мәдәният идарәсе карамагындагы учреждениеләрнең - өстәмә белем бирү оешмаларының югары белемгә ия җитәкчеләре (директорлар һәм укыту-тәрбия эшләре буенча директор урынбасарлары) кертелә. Әлеге номинациядә катнашучыларның яше һәм стажы чикләнми.

4 бүлек. Конкурс сынаулары программасы һәм материалларга таләпләр

12. 2 (читтән торып үткәрелә торган) турда катнашу өчен катнашучылар материалларны саклагычка (Mail.ru, Яндекс.Диск) урнаштыралар яисә видеохостингта һәм «Осталык та, илһам да» Конкурсы» тамгасы белән 2026 елның 5 ноябренә кадәр muzshkola5@yandex.ru электрон почтасына сылтамалар җибәрәләр.

13. Читтән торып үткәрелә торган турының видеоматериалларына таләпләр:

1) «Иң яхшы укытучы», «Иң яхшы концертмейстер» номинацияләре һәм «Һөнәри дебют» подноминациясе:
- визит карточкасы (5 минуттан артык түгел, монтажлау рөхсәт ителә);
- ачык дәрес (35 минуттан артык түгел, төшерү өзлексез, монтажсыз һәм ялгаусыз алып барылырга тиеш);

2) «Иң яхшы җитәкче» номинациясе:
- визит карточкасы (5 минуттан артык түгел, монтажлау рөхсәт ителә);
- эш тәҗрибәсен күрсәтү - үз учреждениесен һәм аны үстерү концепциясен видеопрезентацияләү (30 минуттан артык түгел).

14. Конкурсның 3 (йомгаклау) туры урында үтә торган форматта «5 нче балалар музыка мәктәбе» МАӨББУда базасында (Яр Чаллы шәһәре, Строители бульвары, 9 йорт) узачак. Үткәрү датасы һәм вакыты турында катнашучыларга шәхсән хәбәр ителәчәк.

15. Йомгаклау турына катнашучылар жюри әгъзаларына папкада портфолио тәкъдим итәләр, анда:

1) конкурста катнашучы анкетасы (ирекле формада);

2) соңгы 3 елдагы дипломнар, грамоталар һәм рәхмәт хатлары күчермәләре;

3) осалыкны характерлый торган методик материаллар (соңгы 3 елда эшләнгән кулланмалар, бастырып чыгарылган материаллар, сценарийлар, афишалар);

4) катнашучының соңгы 3 елда яки учреждениедә стаж аз булган очракта бөтен эш чоры өчен һөнәри үсешенең мөһим этапларын тасвирлап, 1 биттән артмаган күләмдә оешма җитәкчесенең тәкъдиме (әлеге документ «Иң яхшы укытучы», «Иң яхшы концертмейстер» номинацияләре һәм «Һөнәри дебют» подноминациясе өчен генә бирелә).

16. Йомгаклау турының урында үтә торган сынаулары эчтәлеге:

- барлык катнашучылар өчен: «сорау-җавап» форматындагы блицтурнир;

- концертмейстерлар өчен (әлеге профиль буенча «Һөнәри дебют» подноминациясен дә кертеп) өстәмә рәвештә практик тәҗрибә күрсәтү (биттән нота текстын уку).

5 бүлек. Катнашучыларны бәяләү критерийлары

17. Жюри катнашучыларны түбәндәге критерийлар нигезендә 10 баллы система буенча бәяли:

1) укытучылар (шул исәптән «Һөнәри дебют» подноминациясе) - һөнәри компетентлык, белем бирү методикасын белү, эш нәтиҗәлелеге (яшь белгечләр өчен - һөнәри үсеш потенциалы һәм динамикасы), инновациялелек һәм креативлык, авторлык стиле, коммуникабельлек, сөйләм грамоталылыгы, гомуми эрудиция, куркынычсызлык һәм хезмәтне саклау кагыйдәләрен белү;

2) концертмейстерлар (шул исәптән «Һөнәри дебют» подноминациясе) - башкару осталыгы, музыкаль текстны белү, артистлык һәм эмоциональлек, ансамбль техникасын һәм төрле уен коралларында уйнау үзенчәлекләрен белү, гомуми эрудиция, куркынычсызлык һәм хезмәтне саклау кагыйдәләрен белү;

3) җитәкчеләр - идарә итү компетентлыгы, үз учреждениесенең нәтиҗәлелегенең төп күрсәткечләрен белү, оешма эшчәнлегенә җәлеп ителү, идарә итүнең нәтиҗәлелеге, инновацион якын килү, коммуникабельлек, лидерлык һәм шәхес сыйфатлары, куркынычсызлык һәм хезмәтне саклау кагыйдәләрен белү.

6 бүлек. Йомгаклар ясау һәм җиңүчеләрне бүләкләү

18. Конкурс йомгаклары барлык конкурс биремнәре балларын кушу һәм уртача балл чыгару юлы белән билгеләнә. Җиңүчеләр һәр номинация/подноминация эчендә билгеләнә (сәнгать төрләре буенча бүлмичә).

19. Конкурс нәтиҗәләре буенча катнашучыларга түбәндәге исемнәр бирелергә мөмкин:

- «Гран-При» - жюри бертавыштан иң күп 10 балл куйган катнашучыга бирелә;

- «I дәрәҗә лауреат» - уртача балл 9,5 тән 9,9 га кадәр булганда;

- «II дәрәҗә лауреат» - уртача балл 9,0 дан 9,4 кә кадәр булганда;

- «III дәрәҗә лауреат» - уртача балл 8,5 тән 8,9 га кадәр булганда.

20. IV һәм V дәрәҗә дипломнар каралмаган.

21. Конкурста төп номинацияләрдә җиңүчеләр (Гран-при ияләре һәм лауреатлар) дипломнар һәм акчалата призлар белән бүләкләнәләр. Акчалата бүләкләрнең база күләме:

- «Гран-При» һәм «I дәрәҗә лауреат» – 15 000 сум;
- «II дәрәҗә лауреат» – 12 000 сум;
- «III дәрәҗә лауреат» – 8 000 сум.

22. Жюри һәм оештыру комитеты хокуклары:

1) әгәр катнашучылар рейтинг буенча тиешле санда балл җыймаса, жюри төп номинацияләрнең теләсә кайсысында призлы (беренче, икенче яки өченче) урыннарны бирмәү хокукына ия;

2) «Һөнәри дебют» махсус подноминациясе ачылган очракта (әлеге Нигезләмәнең 9, 10 пунктлары нигезендә), әлеге подноминация өчен приз фондын финанслау төп номинацияләрдә бирелмәгән яки яңадан бүленгән призлы урыннар фонды акчалары хисабына гамәлгә ашырыла;

3) оештыру комитеты расланган приз фондын конкурсның факттагы нәтиҗәләре буенча номинацияләр һәм «Һөнәри дебют» ачык подноминациясе арасында чараны үткәрүгә бүлеп бирелгән бюджет ассигнованиеләренең гомуми лимиты чикләрендә төзәтмәләр кертергә һәм яңадан бүлергә хокуклы;

4) жюри конкурста катнашучыларны аерым казанышлары өчен махсус дипломнар белән билгеләргә мөмкин (акчалата бүләкләнмичә);

5) жюри әгъзалары нәтиҗәләр рәсми игълан ителгәнче конфиденциальлекне сакларга тиеш һәм үз оешмаларында эшләүче катнашучыларны бәяләргә хокуклы түгел.

23. Бәхәсле очраклар килеп чыкканда жюри рәисе хәлиткеч (өстәмә) тавыш хокукына ия. Жюри карары беркетмәдә теркәлә, ахыргы булып тора һәм яңадан каралмый.

24. Нәтиҗәләрне игълан итү һәм җиңүчеләрне бүләкләү тантанасы йомгаклау Гала-концертында уза.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева